МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

# ПРИКАЗ

# БОЕРЫК

17.01.2024 № 9-осн

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 4 апрелендәге 186-осн номерлы, 2019 елның 3 июнендәге 543-осн номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 624-осн номерлы, 2022 елның 2 февралендәге 77 номерлы, 2023 елның 18 сентябрендәге 419 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карарына ярашлы рәвештә, боерык бирәм:»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләрен «республика

башкарма хакимият органы каршында Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләре белән алмаштырырга;

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы каршында Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А. Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров